Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

21 октябрь 2022 ел №17

Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 14 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Урман-Кәләй авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 14 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Урман-Кәләй авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Урман-Кәләй авылы, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Урман-Кәләй авылы башкарма комитеты җитәкчесе Л.Н. Фәләхиев